**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№4** **22.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Кәкре Елга авыл җирлегенә керүче
Кәтем авылында 2020 елда
үзара салым җыюны кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә, “2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем авылында халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Кәтем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400,00 (дүрт йөз) сум күләмендә, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

. - Кәтем авылы урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);

- Кәтем авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Кәтем авылында юлларны кардан чистарту, (килешү буенча эш өчен түләү);
- Кәтем авылында «Сабантуй» һәм « Яңа ел» бәйрәмен оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу;)
- Кәтем авылы территориясен җәйге вакытта чабып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

3. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: : http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Кәтем авылы, Кәтем ур., 1а йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы: И.М.Мөхәмәтҗанов